ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 гыйнвар, 2019 ел № 29/9

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәне раслау хакында

Россия Федерациясенең Гражданнар кодексы, Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 41 маддәсе, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

**1.** «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хакында Нигезнамәгә, кушымтада карлган тәртиптә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Равилә Гыйлметдин кызы Зариповага Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча инспекциясендә «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәне дәүләти теркәү буенча вәкаләтләр бирергә.

3. Гамәлдән чыккан дип таныргa:

1) Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге ««Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хакындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында» 27/20 санлы Карарын;

2) Шәһәр Советының 2018 елның 08 ноябрендәге ««Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хакындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында» 27/18 санлы Карарын.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
29/9 нчы Карарына
кушымта
24 гыйнвар, 2019 ел

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хакында
Нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Идарә) - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) карамагындагы юридик зат хокукларына ия, гражданнар хәле актларын дәүләт теркәве буенча Татарстан Республикасының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаручы мөстәкыйль орган һәм Россия Федерациясенең гражданнар хәле актларын теркәү бердәм системасының состав өлеше булып тора.

2. Идарәне Оештыручы (Милекче) - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге.

Идарәне оештыручы хокукларын Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы (алга таба - Оештыручы) гамәлгә ашыра.

Идарә милке милекчесе хокукларын Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты башкара (алга таба - Милекче).

3. Идарә үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Гражданнар кодексына, Россия Федерациясе Гаилә кодексына, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законга, 1997 елның 15 ноябрендәге «Гражданлык хәле актлары турында» 143-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Законына, Татарстан Республикасының 2005 елның 30 декабрендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтләр бирү турында»146-ТРЗ санлы Законына, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка хокукый актларына, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына, әлеге

Нигезнамәгә һәм Яр Чаллы шәһәренең башка муниципаль хокукый актларына (алга таба - муниципаль хокукый актлар) таяна.
4. Идарә юридик затларны теркәү турында законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынган мизгелдән юридик зат статусына ия.
5. Идарә мөстәкыйль баланс һәм бюджет сметасын, казначылык органнарында шәхси счетын, салым түләүченең идентификация номерын, үз исеме белән бланклар булдырырга хокуклы. Идарә Россия Федерациясе Дәүләт гербы сурәте төшерелгән түгәрәк мөһергә һәм штампларга ия.
6. Идарә үз исеменнән милек һәм шәхси милек булмаган хокуклар алырга, законнарда, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставында, әлеге Нигезнамәдә билгеләнгән чикләрдә вазыйфалар үтәргә хокуклы.
7. Идарә үз йөкләмәләре буенча үз идарәсендә булган акча средстволары белән җавап бирә. Күрсәтелгән акча средстволары җитмәгән очракта, йөкләмәләр буенча Милекче субсидиар җаваплылыкка ия.
8. Идарәнең тулы рәсми атамасы:
- рус телендә: муниципальное казенное учреждение «Управление записи актов гражданского состояния при Исполнительном комитете муниципального образования город Набережные Челны»;
- татар телендә: «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениеcе.
Идарәнең кыскартылган рәсми атамасы:
- рус телендә: МКУ Управление ЗАГС;
- татар телендә: ГХАТ идарәсе МКУ.
9. Идарәнең адресы: 423831, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Чулман проспекты, 73 йорт.

## 2 бүлек. Идарә эшчәнлегенең предметы һәм максатлары.

10. Идарә эшчәнлегенең предметы һәм максатлары – гражданлык хәле актларын теркәү турында законнар нигезендә гражданнар хәле актларын дәүләт теркәве өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару һәм идарә функцияләрен үтәү.

## 3 бүлек. Идарәнең компетенциясе һәм вәкаләтләре.

11. Әлеге Нигезнамәнең 10 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен, Идарә законнарда билгеләгән тәртиптә түбәндәге функцияләрне (эшчәнлек төрләрен) башкара:

– гражданнар хәле актларын дәүләт теркәвенә алу: туу, үлү, өйләнешү, аерылышу, уллыкка (кызлыкка) алу, атасын билгеләү, исем алыштыру;

– гамәлдәге законнар нигезендә гражданнар хәле актлары язмаларына төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертү буенча материаллар

хәзерләү һәм бәяләмәләр төзү, суд карары буенча акт язмаларын торгызу һәм гамәлдән чыгару;

– федераль законнарда билгеләнгән вакытларда гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү кенәгәсен (актлар кенәгәсен) исәпкә алуны һәм саклауны тәэмин итү;

– югалган акт язмаларын торгызу (гражданнар хәле актларын теркәү турында таныклыкларны);

– гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү фактын раслаучы документларны бирү;

– гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү турында таныклык бланкларын исәпкә алуны һәм саклауны тәэмин итү;

– федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү белән бәйле мәгълүматларны бирү;

– Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү буенча эшчәнлек белән идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органына даими хисап (айлык, кварталга, еллык) бирү, Татарстан Республикасының гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү буенча эшчәнлек белән идарә итү өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү белән бәйле мәгълүматлар тапшыру;

– җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны контрольдә тотуда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына кирәкле ярдәм күрсәтү;

– законнарда каралган тәртиптә өйдә, медицина һәм башка оешмаларда никахны дәүләти теркәүне гамәлгә ашыру;

– башка шәһәрләрнең гражданнар хәле актларын теркәү органнары тәҗрибәсен өйрәнү, мәгълүмат алышуны һәм башка регионнарның гражданнар хәле актларын теркәү органнары белән үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

– гражданнар хәле актларын теркәү мәсьәләләре буенча киңәшмәләр, утырышлар өчен материаллар хәзерләү, комиссияләр төркемнәр эшендә катнашу;

– гражданнар хәле актларын теркәү мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эшләү;

– Идарә компетенциясенә бәйле бәхәсләр буенча судларда катнашу;

– гражданнарны кабул итүне гамәлгә ашыру, гражданнарның телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрен вакытында һәм тулы карауны тәэмин итү, алар буенча карарлар кабул итү һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта гариза бирүчегә җаваплар җибәрү;

– гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү өлкәсендә җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итү максатыннан, шулай ук шәхси мәнфәгатьләре өчен, муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүгә төзелгән контрактлар буенча муниципаль заказчик сыйфатында катнашу;

– муниципаль контрактлар төземичә сатып алынган товарлар реестрын алып бару;

– никахлашучы затлар теләге белән никахны тантаналы шартларда теркәүне оештыру;

– алып баручы, җаваплы оештыручы хезмәтен күрсәтү;

– никахлашуның, исем кушуның яңа йолаларын эшләү;

– тантаналар оештыру буенча хезмәтләр банкында мәгълүмат урнаштырып, мәгълүмати хезмәт күрсәтү;

– Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә гражданнар хәле актларын теркәү органнарына тапшырылган башка функцияләрне (эшчәнлек төрләрен) башкару.

12. Әлеге Нигезнамәнең 10 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары әлеге Нигезнамә һәм башка муниципаль хокукый актлар нигезендә Идарә түбәндәгеләргә хокуклы:

–Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары белән үзара эшләргә;

–Башкарма комитетның вазыйфаи затлары каравына Идарә эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

–Идарә милкен карап тотуга һәм эксплуатацияләүгә оешмалар белән килешүләр, шулай ук идарә компетенцияләре чикләрендә башка килешүләр төзергә;

–Идарә хезмәткәрләрен укыту һәм квалификацияләрен күтәрү максаты белән уздырылган конференцияләрдә, семинарларда катнашырга;

–Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан һәм башка хакимият органнарыннан кирәкле мәгълүмат сорарга һәм алырга;

–гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү буенча эшчәнлек белән идарә итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органыннан һәм Татарстан Республикасы хөкүмәте хакимиятенең башка органнарыннан гражданнар хәле актларын теркәү мәсьәләләре буенча кирәкле консультацион һәм методик ярдәм алырга;

–Әлеге Нигезнамәнең 10 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

13. Идарә түбәндәгеләргә бурычлы:

–гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү турында таныклык бланкларының хисабын алып барырга һәм сакланышын тәэмин итәргә;

–гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү кенәгәсен (актлар кенәгәсен) исәпкә алуны һәм саклауны тәэмин итәргә;

–федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү белән бәйле мәгълүматларны бирергә;

–гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү буенча эшчәнлек белән идарә итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына ай саен хисап бирергә, гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү буенча эшчәнлек белән идарә итү өлкәсендә Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гражданнар хәле актларын дәүләти теркәү белән бәйле мәгълүматлар тапшырырга;

–җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны контрольдә тотуда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органыннарына кирәкле ярдәм күрсәтү;

– Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка вазыйфаларны башкару.

## 4 бүлек. Идарә эшчәнлеген оештыру һәм аңа җитәкчелек итү

14. Идарә эшчәнлеге белән бер генә кеше идарәсе принцибында законнарда һәм әлеге Нигезнамәдә билгеләгән чикләрдә Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә Оештыручы тарафыннан куелучы һәм вазыйфадан азат ителүче Идарә башлыгы җитәкчелек итә.

15. Идарә башлыгы Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында, әлеге Нигезнамәдә һәм аның белән төзелгән хезмәт килешүендә билгеләнгән чикләрдә үз гамәлләре өчен шәхси җаваплылыкка ия.

16. Идарә башлыгы турыдан-туры Башкарма комитет Җитәкчесенә яки аның күрсәтмәсе нигезендә башка вазыйфаи затка буйсына.

17. Идарә башлыгы булмаган чорда аның вазыйфаларын Идарә башлыгы урынбасары башкара.

18. Идарәнең муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче вазыйфаи затлары Идарә башлыгы тәкъдиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе күрсәтмәсе белән вазыйфага билгеләнәләр һәм вазыйфадан азат ителәләр.

19. Идарә башлыгы:

– Идарәне оештыру вакытында билгеләнгән максатларга ирешүне тәэмин итә;

– Дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, физик һәм юридик затлар белән мөнәсәбәттә Идарә мәнфәгатьләрен яклап, ышаныч кагәзеннән башка Идарә исеменнән гамәлләр башкара;

– Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесенә Идарәнең штат саны, Идарә эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүгә финанс средстволарын бүлү, кадрларны сайлау һәм урнаштыру, хәзерләү, квалификацияләрен күтәрү, кызыксындыру, Идарәнең вазыйфаи затлары окладларына өстәмәләр билгеләү, аларга дисциплинар кисәтү ясау буенча тәкъдимнәр кертә;

– Идарә исеменнән килешүләр төзи, ышаныч кәгазе бирә, шәхси счетлар ача, законнарда билгеләнгән чикләрдә башка гамәлләр кыла;

– Идарә эшен планлаштыра;

– Идарә компетенциясе буенча хәзерләнгән документларга һәм материалларга кул куя;

– Идарә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү буенча оештыру эшләре башкара;

– Законнарда һәм әлеге Нигезнамәдә билгеләнгән чикләрдә Идарә милке һәм средстволары белән идарә итү хокукыннан файдалана, үз компетенциясе чикләрендә Идарәнең барлык хезмәткәрләре өчен

мәҗбүри боерыклар чыгара һәм мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирә;

– хисап торышын, хисапны, шул исәптән тиешле органнарга билгеләнгән формаларда бухгалтерлык һәм статистик хисапны вакытында һәм тулы тапшыру өчен җаваплылыкка ия;

– финанс дисциплинасын, Идарә средстволарын һәм матди байлыкларын саклауны тәэмин итә; Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.

5 бүлек. Идарә милке һәм финанслары

20. Идарә милке Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә хисаплана, Идарәнең мөстәкыйль балансында чагылыш таба һәм аңа оператив идарә итү хокукында беркетелә.

Гражданнар хәле актларын дәүләти теркәүгә вәкаләтләрне башкаруга тапшырылган милек исемлеге, шулай ук Идарәнең мондый милеккә хокуклары Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

21. Идарә аңа оператив идарә итү хокукында беркетелгән милеккә законда билгеләнгән чикләрдә эшчәнлеге максатларына, әлеге милекнең билгеләнешенә туры китереп, хуҗа була, аннан файдалана, әгәр закон белән башкасы каралмаса, Милекче ризалыгы белән әлеге милек белән идарә итә.

22. Милекче Идарәгә үзе беркеткән яки Идарә тарафыннан Милекченең средстволарына алынган артык, файдаланылмаган яки билгеләнеше буенча файдаланылмаган милекне кире алырга хокуклы. Идарәдән алынган милек белән Милекче үз ихтыяры буенча идарә итә.

23. Идарәнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге Яр Чаллы шәһәре бюджеты средстволары хисабына расланган бюджет сметасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Гражданнар хәле актларын дәүләти теркәүгә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Идарә эшчәнлеген финанслау Яр Чаллы шәһәре бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты составындагы региональ компенсацияләр фондыннан бирелүче субвенцияләр хисабына башкарыла.

24. Идарә милке һәм финанслары түбәндәгеләр хисабына формалаша:

– финанслауның бюджет чыганаклары;

– Идарәгә оператив идарә хокукында тапшырылган милек;

– Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар белән тыелмаган башка чыганаклар.

25. Идарәнең кредитлар (займнар) бирергә һәм алырга, кыйммәтле кәгазьләр сатып алырга хокукы юк.

26. Идарә, әлеге Нигезнамәгә таянып, керем китерүче эшчәнлекне гамәлгә ашыра ала. Күрсәтелгән эшчәнлектән алынган керемнәр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелә.

## 6 бүлек. Идарә эшчәнлеген исәпкә алу, аңа хисап һәм контроль

27. Идарә үз эшчәнлеге нәтиҗәләрен оператив исәпкә ала, законнарда билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык һәм статистик исәпкә алуны һәм хисапны алып бара.

28. Идарә үз эшчәнлеге турында Башкарма комитет Җитәкчесенә яки ул билгеләгән вәкаләтле вазифаи затка, дәүләт статистикасы органнарына, салым органнарына, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына һәм башка органнарга Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә мәгълүмат бирә.

29. Идарә Башкарма комитет карары белән билгеләнгән тәртиптә эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыра.

30. Вазыйфаларны тиешенчә үтәмәгән һәм хисапны үзгәрткән өчен Идарәнең вазыйфаи затлары гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылыкка ия.

## 7 бүлек. Идарәне ликвидацияләү һәм үзгәртеп оештыру тәртибе

31. Юридик зат буларак Идарәне ликвидацияләү һәм үзгәртеп оештыру Оештыручы карары буенча Россия Федерациясе законнарында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

32. Идарә федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә суд карары буенча ликвидацияләнергә мөмкин.

33. Идарә ликвидацияләнгән очракта, аның кредиторлар таләбен канәгатьләндергәннән соң калган милке Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге милкенә күчерелә.

## 8 бүлек. Мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу һәм булдырмау

34. Мәнфәгатьләр каршылыгы – ул Идарә хезмәткәренең шәхси кызыксынуы нәтиҗәсендә вазыйфаи бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясарга мөмкин булган хәл, андый хәл булганда, Идарә хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм ул эшләгән Идарәнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында Идарәнең милкенә һәм (яйсә) абруена зыян салучы каршылыклыр туа яйсә туарга мөмкин.

35. Идарә хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясаучы яки йогынты ясарга мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык – ул Идарә хезмәткәре тарафыннан, хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле рәвештә, үзе яки өченче затлар өчен акча, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яки милек характерындагы хезмәтләр рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге.

36. Идарә башлыгы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенә вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык хакында хәбәр итәргә тиеш.

37. Идарә хезмәткәре Идарә башлыгына вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык хакында хәбәр итәргә тиеш. Идарә башлыгына хәбәр итү тәртибе, хәбәрдә бирелүче мәгълүматлар исемлеге, мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрләрне теркәү тәртибе Идарә башлыгы тарафыннан билгеләнә.

Әлеге Нигезнамәгә үзгәрешләр һәм өстәлмәләр кертү тәртибе

38. Әлеге Нигезнамәгә үзгәрешләр һәм өстәлмәләр кертү Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы карары белән гамәлгә ашырыла.

39. Әлеге Нигезнамәгә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәлмәләр законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве көненнән үз көченә керә.

40. Әлеге Нигезнамә белән җайга салынмаган сораулар Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә җайга салына.